СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МИЧУРИН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 2 октябре № 25

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2013 елның 21 ноябрендәге 21А номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2013 елның 21 ноябрендәге 21А номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1 статьяның 19 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«кызыл линияләр - гомуми файдаланудагы территорияләрнең чикләрен билгеләүче һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртергә яки юкка чыгарылырга тиешле линияләр»;

**12 статьяның 2 пунктын 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**: «2. Шәһәр төзелеше зонасы картасында территориаль зоналарның чикләре билгеләнә. Территориаль зоналар чикләре һәр җир участогының таләпләренә, җир законнары нигезендә чикләре территориаль зоналар чикләрен кисәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш, бары тик бер территориаль зонага гына туры килүе таләпләренә туры килергә тиеш.»;

**14 нче статьяда:**

**а) түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга**: «1.1. Әгәр мондый кире кагу рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектларының бер яки берничә чик параметрларын бер тапкыр үзгәртү, конкрет территориаль зона өчен шәһәр төзелеше Регламентында билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү максатларында, ун проценттан артмаган очракта, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы. ».

б) **4 бүлектә** беренче җөмләне «әлеге статьяның 1_1 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск районы Мичурин авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Ә Иванова